**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге Советы өченче чакырылыш утырышы**

**Карары**

**11 апрель 2019 ел** **№ 211** **Үзәк авылы**

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге Советының 2014 елның 25 ноябрендә кабул ителгән «Җир салымы турында»гы 192 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында.**

Россия Федерациясе Салым кодексына, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131 санлы Федераль законга туры китереп, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 1.Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге Советының 2014 елның 25 ноябрендә кабул ителгән «Җир салымы турында»гы 192 санлы карарының 4 өлешен, түбәндәге редакциядә биреп, үзгәреш кертергә:

1. 1. «4. Түбәндәге категория салым түләүчеләргә җир салымы буенча ташламалар бирергә:

- төзелеш материаллары җитештерү объектлары урнашкан җир участоклары милекчеләренә, җир участогының кадастр бәясеннән 0,4 процент күләмендә киметелгән салым ставкасы кулланып.»

2. Әлеге карар 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла һәм 2019 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Карар гамәлдәге законнар нигезендә көченә керә.

4. Карар гамәлдәге законнарга туры китереп бастырып чыгарыла.

Үзәк авыл
җирлеге башлыгы В.Н. Котников